Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2024 елның 11 ноябре №5

**«Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 22 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

2. 2024 елның 22 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Туембаш авылы, Ленин урамы, 87 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 2000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туембаш авылының Ленин

урамындагы вак таш һәм асфальт түшәлгән юлларны төзекләндерү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру, Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, урнаштыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират территориясен карап тоту, киртәләү, төзекләндерү, Туембаш авылындагы зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр);

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны карап тоту һәм урнаштыру, Туембаш авылын урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документация, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрләрен, су җыю манараларын төзү, тоту һәм ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, су җыю манараларын буяу, материаллар сатып алу, Туембаш авылының су саклау зоналарын төзекләндерү, проект-смета документлары, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су җыю манараларын карап тоту буенча башка төр эшләр);

- җир асты сулары чыга торган урыннарны (чишмәләрне) төзекләндерү (Туембаш авылы чишмәләрен төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, проект-смета документлары, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Туембаш авылында янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, проект-смета документлары, янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне ремонтлау һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Туембаш авылы территориясен төзекләндерү, агачларны һәм куакларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Туембаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов